БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2021 ел № 70

**Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясының 1 пункты һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясының 2 пункты нигезендә, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясының 1 пункты һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән барлыкка килә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясының 2 пункты нигезендә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән, Балтач районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә авыл хуҗалыгы җирләрен гражданнар милкенә түләүсез тапшыру нәтиҗәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте**:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын 3,5 гектар күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка хәбәр итәргә: http://baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин